ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.08.2022 Олы Кайбыч ав. № 369

Хисап чорында «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керә торган «Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча белем алган гражданнар саны («Мәгариф» тармагы буенча)» хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән үсеш күрсәткечен җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын раслау турында

«2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы, «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указлары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Хисап чорында «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керә торган «Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча белем алган гражданнар саны («Мәгариф» тармагы буенча)» хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән үсеш күрсәткечен җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы И.И. Хәмидуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы,
Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең
беренче урынбасары Э.Х.Заһидуллина

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
«25» 08. 2022
№369 карарына кушымта

**Хисап чорында «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керә торган «Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча белем алган гражданнар саны («Мәгариф» тармагы буенча)» хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән үсеш күрсәткечен җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Регламентны җайга салу предметы.

Әлеге хисап чорында «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керә торган «Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча белем алган гражданнар саны («Мәгариф» тармагы буенча)» хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән үсеш күрсәткечен җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламенты Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламенты «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы карары, «Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы турында» 2009 елның 31 декабрендәге 920 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы «Контроль» модуленең эшләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 18 апрелендәге 361 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә эшләнгән һәм хисап чорында «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керә торган «Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча белем алган гражданнар саны («Мәгариф» тармагы буенча)» хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән үсеш күрсәткечен җыю һәм мониторинглау тәртибен билгели.

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ (алга таба - мәгариф бүлеге) Кайбыч

муниципаль районындагы декомпозициялəнгəн күрсəткечлəрне жыю һəм мониторинглау өчен җаваплылык үзəге булып тора.

1.2. Белешмə мəгълүмат.

Әлеге регламент максатлары өчен Россия Федерациясе Хөкүмəтенең «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дəүлəт хакимиятенең иң югары башкарма органнары җитəкчелəре) эшчəнлегенең һəм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчəнлегенең нəтиҗəлелеген бəялəү өчен, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмəтенең 2019 елның 17 июлендəге 915 номерлы карарының аерым нигезлəмəлəренең үз көчлəрен югалтуын тану методикаларын раслау турында» 2021 елның 3 апрелендəге 542 номерлы карары белəн кертелгəн, хисап чорында «Мəгариф дəрəҗəсе» күрсəткече составына керə торган «Өстəмə һөнəри программалар һəм һөнəри белем бирү программалары буенча белем алган гражданнар саны («Мəгариф» тармагы буенча)» хисап чорында муниципаль дəрəҗəгə декомпозициялəнгəн үсеш күрсəткечен җыю һəм мониторинглау механизмы күрсəткечлəрен исəплəү методикасында билгелəнгəн терминнар кулланыла.

## 2. Исəплəү стандарты, җыю тəртибе һəм мəгълүматлар бирү

Декомпозиялəнгəн ярдəмче күрсəткечне исəплəп чыгару өчен түбəндəге мəгълүматлар кулланыла:

өстəмə һөнəри программалар һəм һөнəри белем бирү программалары буенча белем алган гражданнар саны («Мəгариф» тармагы буенча).

Мəгълүматлар өстəмə һөнəри программалар һəм һөнəри белем бирү программалары буенча хезмəтлəр күрсəтүче мəгариф оешмасы, «Татарстан Республикасында электрон белем» дəүлəт мəгълүмат системасына, «Квалификация арттыру» модуленə edu.tatar.ru кертелə.

Мəгариф бүлеге җаваплы хезмəткəре хисап чорында түбəндəге күрсəткечлəр буенча белешмəлəр җыя:

«Татарстан Республикасында электрон мəгариф» дəүлəт мəгълүмат системасыннан «Квалификация арттыру» модуле edu.tatar.ru - «Хисаплар» бүлегеннəн йөклəмə нигезендə.

Кайбыч муниципаль районы буенча мəгълүмат Татарстан Республикасы Мəгариф һəм фəн министрлыгы адресына Татарстан Республикасының электрон документлар əйлəнеше бердəм ведомствоара системасында рəсми хат белəн тапшырыла.

## 3. Мәгълүматларның составы, бирелү вакыты һәм рәвеше

«Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча белем алган гражданнар саны («Мәгариф» тармагы буенча) - күрсәткеч буенча мәгълүматлар бирү рәвеше

| № т/б | Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча хезмәтләр күрсәтүче оешма исеме («Мәгариф» тармагы буенча) | Үлчәү берәм леге (кеше) | Мәгълүмат бирү срогы хисап аеннан соң килүче айның 1 числосына кадәр квартал саен | Өстәмә һөнәри программалар һәм һөнәри белем бирү программалары буенча хезмәтләр буенча укытылган гражданнар саны («Мәгариф» тармагы буенча) |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |